| | |
|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**БОЕРЫК**

29.06.2018 № 87-од

Казан ш.

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 13.09.2016 № 069-од боерыгы белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 мартындагы № 397 карарына туры китерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында» Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының 13.09.2016 № 069-од боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 12.12.2017 № 150-од боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында (алга таба – Комитет) «Россия Федерациясе дәүләт граждан

хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 22 статьясы, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 мартындагы № 397 карары белән (алга таба – № 397 карар) расланган Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар уздыруның бердәм методикасы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартындагы № ПУ-127 Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 11 декабрендәге № ПУ-1192 Указы нигезендә уздырыла.

Конкурс Комитетта конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның (алга таба – кандидатлар) һөнәри дәрәҗәсен, аларның граждан хезмәтенең тиешле вазыйфаларын биләү өчен билгеләнгән квалификацион таләпләргә (алга таба – тиешенчә квалификацион таләпләр, кандидатларны бәяләү) туры килү-килмәвен бәяләү максатларында уздырыла.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Дәүләт комитетында конкурс уздыру өчен Дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе эшенең объективлыгын һәм бәйсезлеген арттыру максатларында Комитет рәисе карары белән даими рәвештә (ел саен) аның составы яңартыла. Комиссия составы үзгәргәндә Дәүләт комитеты боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә»;

2.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе карары һәм кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән № 397 карар белән расланган формалар буенча рәсмиләштерелә»;

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IV. Конкурс уздыру методикасы

4.1. Конкурс уздырганда кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына нигезләнгән, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәүче конкурс биремнәре һәм процедурлары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Дәүләт комитетында граждан хезмәте вазыйфаларына карата белдерелүче квалификацион таләпләр нигезендә эшләнгән.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийларының якынча исемлеге һәм кыскача тасвирламасы әлеге Нигезләмәнең 5 нче кушымтасында китерелә.

Конкурс уздырылучы вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә бәйле рәвештә конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәртелергә дә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу аларның конкурс биремнәрен үтәүләре һәм конкурс процедураларын узулары нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗәләр кандидатлар исемлеге баллары буенча рангларга бүлү (рейтинг) рәвешендә тәкъдим ителә.

4.3.1 Кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның квалификацион таләпләргә туры килү-килмәвен бәяләү өчен конкурс процедуралары барышында федераль законга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәүче бәяләү методлары да кулланылырга мөмкин.

4.4. Конкурс ике этапта уздырыла.

4.4.1. Беренче этапта Комитетның рәсми сайтында һәм «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составына идарәнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы) конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында мәгълүмат, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) атамасы, шушы вазыйфаны биләү өчен квалификацион таләпләр, документлар кабул итү урыны һәм вакыты, кандидатлар Комитетта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен тапшырырга тиешле документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә (әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымта), әлеге документларны кабул итү тәмамлану срогы, конкурс уздыруның күз алдында тотылучы датасы, урыны һәм аны уздыру тәртибе, бәяләү методлары турында белешмәләрне, граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычлардан, хокуклардан һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыктан, граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләреннән, алдан уздырылган квалификацион тестка (алга таба – алдан тест) сылтамадан торган, дәүләт хезмәте өлкәсендә Дәүләт мәгълүмат системасы порталында урнаштырылган вазыйфаи регламент нигезләмәләрен, башка мәгълүмат материалларын.

Дәүләт комитетында конкурс оештыру «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең бердәм дәүләт кадрлар составы мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы) кулланып гамәлгә ашырыла.

Кандидатлар өчен конкурслар барышында кулланыла торган бәяләү методлары турында мәгълүмат алу мөмкинлеген арттыру, шулай ук үзлегеннән әзерлекне һәм кандидатның һөнәри дәрәҗәсен арттыруны мотивацияләү максатларында, ул үзенең һөнәри дәрәҗәсен мөстәкыйль бәяләү өчен конкурс кысаларыннан тыш алдан квалификацион тест (алга таба – алдан тест) уза ала.

Алдан тестка кандидатларның Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен), Россия Федерациясе Конституциясе нигезләрен, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын белү дәрәҗәсен һәм мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендәге күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәр керә. Кандидаталарга аны узу мөмкинлеге түләүсез була.

Кандидатның алдан тест узуы нәтиҗәләре Конкурс комиссиясе тарафыннан игътибарга алынмый һәм аны конкурста катнашу өчен документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

4.4.2. Кандидатлар граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) тапшырган документларны тикшергәннән соң, Дәүләт комитетының хокук һәм кадрлар эше бүлеге Дәүләт комитеты рәисенә гражданнарны (граждан хезмәткәрләрен) конкурста катнашуга кертү йә конкурста катнашудан дәлилләнгән баш тарту турында карар кабул итү өчен тәкъдим кертә.

Конкурсның икенче этабын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турындагы карар граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшергәннән соң, шулай ук дәүләт серен һәм бүтән закон белән сакланылучы серне тәшкил итүче белешмәләрне алуны рөхсәт итү кирәк булган очракта, аларны рәсмиләштергәннән соң, Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан кабул ителә. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланган көннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча уздырыла, дәүләт серен һәм бүтән закон белән сакланылучы серне тәшкил итүче белешмәләрне алуны рөхсәт итү кирәк булган очракта, конкурсның икенче этабын уздыру срогы Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә каршы килерлек хәлләр ачыкланганда, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында аңа Дәүләт комитеты рәисе язма рәвештә хәбәр итә (әлеге Нигезләмәгә 6 нчы кушымта). Әгәр граждан конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турындагы хәбәрнамә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салып, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, аңа электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.4.3. Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кертелмәгән Россия Федерациясе законнары нигезендә бу карарга карата шикаять белдерергә хокуклы.

4.4.4. Конкурсның беренче этабы тәмамлану шарты – граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының дәүләт хезмәте вазыйфасына) билгеләнгән таләпләргә туры килүче кимендә ике кандидат булу, бу киләчәктә кандидатларны сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Хокук һәм кадрлар эше бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көннән дә соңга калмыйча Дәүләт комитетының рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы порталында конкурсны уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар исемлеген урнаштыра һәм тиешле хәбәрләрне язма рәвештә кандидатларга җибәрә, бу чакта конкурста катнашу өчен электрон рәвештә документлар тапшырган кандидатларга көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салып, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, аңа электрон документ рәвешендә җибәрә.

Кандидатлар булмаган очракта яисә квалификацион таләпләргә туры килерлек бер генә кандидат булганда, конкурс булмаган дип санала. Бердәнбер кандидат булганда аңа конкурс комиссиясе карары буенча таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә конкурс булмаган дип танылу турында язма рәвештә хәбәр ителә.

4.4.5. Икенче этапта конкурс түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

а) конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары бәяләнә;

б) конкурста җиңүчене Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләп кую (кадрлар резервына кертү) турында Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан карар кабул ителә.

4.4.6. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатлар тапшырган документлар нигезендә аларның белеме турындагы, граждан яисә бүтән дәүләт хезмәте узу турындагы, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы белешмәләрне, шулай ук конкурс процедуралары нигезендә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килмәслек методларын кулланып, шул исәптән Дәүләт комитетында кандидатлар дәгъва кыла торган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә тестлаштыру һәм индивидуаль әңгәмә кулланып бәяли. Конкурс уздырылучы вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә бәйле рәвештә төрле методлар кулланылырга мөмкин. Бу чакта кандидатлар белән тестлаштыру һәм индивидуаль әңгәмә барлык кандидатлар өчен дә мәҗбүри була.

4.4.7. Реферат һәм бүтән язма эш (алга таба – Эш) язу өчен конкурс уздырылучы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резрвына кертүгә конкурс уздырылучы граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) вазыйфаи бурычлардан, шулай ук әлеге вазыйфаларны биләү өчен квалификацион таләпләрдән чыгып төзелгән сораулар файдаланыла. Рефератлар темасы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылган очракта, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылучы дәүләт органының структур бүлекчәсе җитәкчесе

тарафыннан билгеләнә, кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылган очракта, кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылучы граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри эшчәнлек өлкәсе гамәлгә ашырылучы дәүләт органының структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм конкурс комиссиясе рәисе белән килештерелә.

Реферат түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

реферат күләме – 7 биттән алып 10 биткә кадәр (титул битеннән һәм файдаланылган әдәбият исемлегеннән гайре);

шрифт – Times New Roman, күләме 14, бер интервал аша.

Рефератта файдаланган чыганакларга сылтама булырга тиеш.

Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылган очракта, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылучы дәүләт органының структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан рефератка язма бәяләмә бирелә, кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылган очракта, кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылучы граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри эшчәнлек өлкәсе гамәлгә ашырылучы дәүләт органының структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан бәяләмә бирелә. Бу чакта объектив бәяләү уздыру максатларында, әзерләнгән рефератның һәм бүтән язма эшнең анонимлыгы тәэмин ителә.

Эш кандидатлар тарафыннан конкурс комиссиясе секретарена конкурс комиссиясе утырышын уздырырга кимендә 5 календарь көн кала тапшырыла.

Эшне бәяләү нәтиҗәләре Дәүләт комитетының Эш темасын билгеләүче структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан, йомгак баллны күрсәтеп, түбәндәге критерийлар буенча кыскача белешмә рәвешендә рәсмиләштерелә:

| № | Критерийлар | Бәяләү |
|---|---|---|
| 1 | рәсмиләштерүнең билгеләнгән таләпләренә туры килү | 0 – 1дән, монда<br>0 – туры килми<br>1 – туры килә |
| 2 | теманы ачу | 0 – 1дән, монда<br>0 - ачылмаган<br>1 - ачылган |
| 3 | аналитик сәләтләр, фикерләү мантыйклыгы | 0 – 1дән, монда<br>0 – түбән дәрәҗә<br>1 – җитәрлек дәрәҗә |
| 4 | бирелгән тема буенча тапшырылган тәкъдимнәрнең нигезлелеге һәм практикада гамәлгә ашырылышы | 0 – 5дән, монда<br>0 – гамәлгә ашыру мөмкин түгел,<br>5 – хәзерге заман шартларында гамәлгә ашыру дәрәҗәсе югары |
|  | хокукый һәм лингвистик гыйлем | 0 – 2дән, монда |

| | | |
|---|---|---|
| 5 | | 0 – түбән дәрәҗә<br>1 – мөмкин дәрәҗә<br>2 – югары дәрәҗә |

Эшне бәяләгәндә максималь балл 10 балл тәшкил итә.

Объектив бәяләү максатларында кандидатлар тарафыннан әзерләнгән Эшләрнең анононимлыгы тәэмин ителә.

4.4.8. Тестлаштыру юлы белән Россия Федерациясе граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертүгә кандидатларның Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен), Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләрен, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын, мәгълүмат-коммуникация технологияләрен белү дәрәҗәсе һәм күнекмәләре, шулай ук һөнәри эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле рәвештә белемнәре һәм күнекмәләре бәяләнә.

Тестлаштыру узуны оештыру Дәүләт комитетына кергән заявкалар нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Бердәм кадрлар мәгълүмат системасында гамәлгә ашырыла.

Тестлаштыруга заявка Бердәм кадрлар мәгълүмат системасында конкурс комиссиясе утырышы башланырга ике атнадан да соңга калмыйча формалаштырыла.

Тестлаштыру «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 11 декабрендәге № ПУ-1192 Указы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тестлаштыру нәтиҗәләре Бердәм кадрлар мәгълүмат системасында чагылдырыла.

4.4.9. Кандидатлар белән индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан уздырыла.

Индивидуаль әңгәмә кандидатларның аларның киләчәк һөнәри хезмәт эшчәнлеге темасы буенча Конкурс комиссиясе әгъзалары биргән сорауларга телдән җавапларыннан гыйбарәт, аның барышында Конкурс комиссиясе, граждан хезмәте вазыйфасына карата тиешле квалификацион таләпләрдән һәм бу вазыйфа буенча башка вазыйфаи регламент нигезләмәләреннән, шулай ук әлеге Нигезләмә һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының законнары белән билгеләнгән бүтән нигезләмәләрдән чыгып, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяли.

Индивидуаль әңгәмә барышында конкурс комиссиясе тарафыннан кандидат белән аның конкурс биремнәрен үтәве һәм конкурс процедураларын узуы нәтиҗәләре турында фикер алышу уздырыла, аның һөнәри дәрәҗәсен билгеләү максатларында сораулар бирелә.

Алдан индивидуаль әңгәмә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылучы дәүләт органының структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан яисә кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылган очракта, кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылучы граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри эшчәнлек өлкәсе гамәлгә ашырылучы дәүләт органының структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан уздырылырга мөмкин.

Алдан индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре турында бу әңгәмә конкурс комиссиясе утырышына кадәр уздырылган очракта, конкурс комиссиясенә аны уздыручы зат конкурс комиссиясе утырышы барышында телдән нотык рәвешендә хәбәр ителә.

4.4.10. Кандидатлар конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм конкурс комиссиясе утырышын уздырганда Дәүләт комитеты рәисе карары буенча тиешле конкурс процедураларын уздыруның видео-һәм (яисә) аудиоязмасы йә стенограммасы алып барыла.

Кандидат белән индивидуаль әңгәмә тәмамлангач, һәр конкурс комиссиясе әгъзасы конкурс бюллетененә кандидатны бәяләү буенча әлеге Нигезләмәнең 7 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча төзелгән нәтиҗәсен кертә.

4.4.11. Рейтингны киләчәктә 10 баллы система белән исәпләп чыгару өчен конкурс бюллетеньнәре, шулай ук нәтиҗәләрне билгеләү рәсмиләштерелә.

Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар баллын исәпләп чыгару һәм шәхси-һөнәри һәм идарәчел ресурсларны бәяләү санлы күрсәткечләрне кушу юлы белән уздырыла.

4.5. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча конкурс комиссиясе карары белән һәм кадрлар резервына кертүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе (алга таба – утырыш беркетмәсе) белән рәсмиләштерелә, аңа комиссия рәисе, рәисе урынбасары, секретаре һәм утырышта катнашучы әгъзалар имза сала. Конкурс комиссиясе карары һәм утырыш беркетмәсе № 397 карар белән расланган формалар буенча төзелә.

4.6. Конкурска йомгак ясау һәм Дәүләт комитетында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат турында карар кабул итү өчен нигез кандидатлар алган тавышлар саныннан, кандидатлар дәгъва кылучы вазыйфа булган структур бүлекчәсе җитәкчесе (Дәүләт комитеты җитәкчесе) фикереннән гыйбарәт була.

Конкурста ике яисә аннан артык катнашучы иң күп балл җыйган очракта, конкурс комиссиясе рәисе фикере хәлиткеч була.

4.7. Әгәр конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтнең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын уздыру турында карар кабул итәргә яисә кабат конкурс уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.8. Граждан хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча граждан хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүчене билгеләү турында Дәүләт комитеты боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Конкурс комиссиясе шулай ук Дәүләт комитеты граждан хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны кадрлар резервына кертү турында тәкъдим характерындагы карар кабул итәргә хокуклы. Бу кандидат җыйган балларның гомуми суммасы максималь баллның кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Кандидатны граждан хезмәтенең теге яисә бу төркеме вазыйфасын биләү өчен граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына караган кадрлар резервына кертү турында боерык кандидат риза булган очракта чыгарыла, ул язма рәвештә йә көчәйтелгән квалификациялнгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.9. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр конкурс тәмамланган көннән 7 көнлек срокта кандидатларга язма рәвештә җибәрелә, бу чакта конкурста катнашу өчен электрон рәвештә документлар тапшырган кандидатларга көчәйтелгән квалификацияле электрон имза салып, дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, аңа электрон документ рәвешендә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук срокта Дәүләт комитетының рәсми сайтында һәм Дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасы порталында урнаштырыла.

4.10. Конкурста катнашуга кертелмәгән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар һәм конкурста катнашучы кандидатлар документлары аларга конкурс тәмамланган көннән өч көн эчендә язма гариза рәвешендә кире кайтарылырга мөмкин. Бу срок тәмамланганчы документлар хокук һәм кадрлар эше бүлегендә саклана, ул киләчәктә юк ителергә тиеш.

Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар хокук һәм кадрлар эше бүлегендә өч көн буена саклана, ул киләчәктә юк ителергә тиеш.

4.11. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс уздыру урынына бару һәм аннан кире кайту, торак урынын яллау, яшәү, элемтә чаралары хезмәт күрсәтүеннән һәм башкалардан файдалану) кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4.12. Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидат Россия Федерациясе законнары нигезендә конкурс комиссиясе карарына карата шикаять белдерергә хокуклы.»;

Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 7 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасының
Архив эше буенча дәүләт
комитетының 13.09.2016 г. №

069-од боерыгы белән расланган
Нигезләмәгә 7 нче кушымта

Конкурс бюллетене
«___»_____________ 20__ ел

1. ______________________________________________
биләү өчен конкурс уздырылучы вазыйфалар атамасы яисә
кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылучы вазыйфалар төркеме атамасы

Индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатларга бирелгән баллар (максималь балл 10 балл).

| Кандидатның Ф.Ис. Ат ис. | балл | Куелган баллны кыскача дәлилләү (кирәк чакта) |
|---|---|---|

2. ______________________________________________
биләү өчен конкурс уздырылучы вазыйфалар атамасы яисә
кадрлар резервына кертүгә конкурс уздырылучы вазыйфалар төркеме атамасы

Индивидуаль әңгәмә нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафынна кандидатларга бирелгән баллар (максималь балл 10 балл тәшкил итә).

| Кандидатның ФИс. Ат ис. | балл | Куелган баллны кыскача дәлилләү (кирәк чакта) |
|---|---|---|

_______________________________________ ________
Конкурс комиссиясе әгъзасы ФИс.Ат.ис. имза»

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис Г.З. Габдрахманова